ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**18.08.2015**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1732**

«2015-2016 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында

Зеленодольск муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү өчен уңай шартлар тудыру максатларында Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2015-2016 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын (1 нче кушымта) расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы А.Н. Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм интернет челтәрендәге сайтта бастырып чыгарырга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.Р. Гафиятуллинга йөкләргә.

Җитәкче С.Г.Егоров

«18» 08.2015 ел № 1732
карарына
кушымта

# «2015-2016 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программа

Зеленодольск ш., 2015

## ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Муниципаль программа исеме | 2015-2016 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>«2015 елда агросәнәгать комплексына ярдәм чаралары турында» 2015 елның 26 февралендәге 120 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты. |
| Программаны эшләүче | «Зеленый Дол» инвестиция үзәге» АУ<br>Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый анализ бүлеге |
| Программаның максатлары | Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр бирү юлы белән авыл хуҗалыгын үстерү. |
| Программаның бурычлары | 1. Хуҗалык итүнең һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның кече формалары санын арттыру.<br>2. Хуҗалык итүнең кече формаларын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны ЗМР икътисадының терлекчелек тармагына җәлеп итү. |
| Программаны тормышка ашыру срогы | 2015-2016 еллар |
| Программаны башкаручылар | «Зеленый Дол» инвестиция үзәге» АУ<br>Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты.<br>Авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары. |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла:<br>2015г - 540 000 сум<br>2016г. - 648 000 сум |
| Программаның ахыргы нәтиҗәләре һәм күрсәткечләре | 1. Сөт продукциясен җитештерү күләмен арттыру<br>2. Терлекчелекнең тулаем продуктын арттыру<br>3. Хуҗалык итүнең һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның кече формалары санын арттыру |
| Программаның үтәлешен контрольдә | Программаны гамәлгә ашыру Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты |

| | |
|---|---|
| тоту системасын гамәлгә ашыру | тарафыннан координацияләнә. |

## 1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә хуҗалык итүнең кече формалары эшчәнлегенә анализ.

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә 01.01.2015 ел торышы буенча 1669 кече эшкуарлык субъекты теркәлгән, шуларның 87 се авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшли. Индивидуаль эшмәкәрләр 3168 исәпләнә, шуларның 86 сы авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшли.

Зеленодольск муниципаль районы буенча кече бизнес эшчәнлеге өлкәләре әйләнешендә авыл хуҗалыгы өлеше 2,38 % тәшкил итә .

Районда авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең гомуми мәйданы 79,9 га тәшкил итә, шул исәптән 72 мең га авыл хуҗалыгы җирләре, шуларның 52,1 мең гектары сөрелгән җирләр.

2014 елда авыл хуҗалыгы эшчәнлегеннән төп капиталга инвестицияләр күләме 757,78 млн. сум тәшкил итте.

Соңгы елларда Зеленодольск муниципаль районында авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеге кимү тенденциясе күзәтелә, бу авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәренең кимүе белән раслана.

Районда кече хуҗалык формаларын үстерүнең тоткарлык факторлары түбәндәгеләр булып тора:

- Авыл хуҗалыгының аеруча перспективалы тармаклары турында халыкның аз хәбәрдар булуы ;
- Хуҗалык эшчәнлеген алып баруның нәтиҗәле ысуллары турында халыкның аз хәбәрдар булуы ;
- Эшкуарлык эшчәнлеген алып бару мәсьәләләрендә халыкның юридик яктан наданлыгы;
- Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең финанс тотрыксызлыгы.

Авыл хуҗалыгы халык хуҗалыгының тормыш өчен мөһим тармагы булып тора, һәм ул шәхси ярдәмче хуҗалыклардан башка яши алмый. Өч һәм аннан да күбрәк савым сыеры булган шәхси ярдәмче хуҗалыклар сыер саву белән бәйле кыенлыклар белән очраша, алардан саву җайланмаларын кулланып котылып була, алар ярдәмендә хезмәт чыгымнары кими, саву процессы тизләнә, сөт саву һәм аның сыйфаты да арта. Мондый аппаратларның бәясе артык югары һәм еш кына шәхси ярдәмче хуҗалыкның көченнән аны алырга авыррак. Шуңа бәйле рәвештә программа төзелә, аның чаралары шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга шәхси саву аппаратлары сатып алу өчен аларның бәясеннән 60% күләмендә субсидияләр бирүне күздә тота.

Бер саву аппаратының бәясе 18 000 сум тәшкил итә. Саву аппараты бәясенең 40% ы 7 200 сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләнә, Министрлар Кабинетының 2015 елның 26 февралендәге «2015

елда агросәнәгать комплексына ярдәм чаралары турында» 120 номерлы карары нигезендә, калган 60% саву аппараты бәясеннән (10 800 сум) Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләү планлаштырыла. Зеленодольск районында саву җайланмаларына ихтыяҗы кискен булган 50 шәхси ярдәмче хуҗалык исәпләнә, шул рәвешле шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы гражданнарга 2015 елда индивидуаль саву аппаратлары сатып алуга чыгымнар өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан 540 000 сум (10 800 * 50) бүлеп бирү планлаштырыла.

2016 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарны 60 берәмлеккә кадәр арттыру фаразлана, шулай итеп, чыгымнарны каплау өчен субсидияләрне Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан 648 000 сум (10 800 * 60) бүлеп бирү планлаштырыла.

Сөт җитештерүчеләр өчен риск чыганагы булып башлангыч чыгымнарны кертү һәм
әзер продукция чыгару арасында зур вакытлыча интервал тора. Сөт җитештерү күләмнәрен арттыру озак вакыт дәвамында үзенә тотылган чыгымнарны кайтарып алуга шактый акча җәлеп итүне таләп итә. Сөтне озак вакыт транспортта йөрткән һәм эшкәртелмәгән килеш саклау өчен яраксызга әйләнү сәбәпле, бу кыска вакытлы чорда бәяләү буенча тәкъдимнең эластиклыклы булмавы белән аңлатыла. Моннан тыш, ел фасыллары буенча сөткә бәяләр үзгәреп тора Мәсәлән, 1 л сөткә сатып алу бәясе динамикасы гыйнвар аеннан март аена кадәр тотрыклы, апрельдән июньгә кадәр кимүгә тенденциясе күзәтелә, августтан алып декабрьгә бәяләр арту күзәтелә һәм ул максималь әһәмияткә ия, чөнки сөт җибәрү августта сөт ташу белән чагыштырганда 81% ка кими.

Рискны минимальләштерү максатларында, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар үз продукциясен шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сөт җыючы «Нур» МУП сата алалар.

Авыл хуҗалыгын алга таба үстерүнең актуаль проблемаларының системалы һәм үзара бәйләнешле характеры аларны үсешнең максатлары, бурычлары һәм төп индикаторлары системасын формалаштыруны, өстенлекле юнәлешләр һәм программа чараларын эшләүне, финанслауның кирәкле күләмнәрен билгеләүне, бюджет һәм бюджеттан тыш ресурсларны максатлар һәм бурычлар буенча бүлүне күздә тоткан дәүләт идарәсенең программа-максатчан методы принципларында хәл итүне таләп итә.

## 2. Программаның төп максатлары һәм бурычлары.

Муниципаль программаның максаты: шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр бирү юлы белән авыл хуҗалыгын үстерү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Хуҗалык итүнең һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның кече формалары санын арттыру.

2. Хуҗалык итүнең кече формаларын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны ЗМР икътисадының терлекчелек тармагына җәлеп итү.

**Финанслау күләме һәм чыганаклары**

Программа чараларын финанслау тиешле финанс елына Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

**Программаны тормышка ашыру срогы**

2015 - 2016 еллар

## 3. Максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләр.

| Индикаторлар / еллар | 2015 | 2016 | 2017 |
|---|---|---|---|
| Мөгезле эре терлек үрчетү белән шөгыльләнүче шәхси ярдәмче хуҗалыклар саны,берәмлек | 12913 | 12928 | 12948 |
| Сөт саву, тн. | 9677,4 | 12370,5 | 14878,9 |
| Эре мөгезле терлекләр санын арттыру, мең баш | 18,24 | 18,73 | 19,25 |

## 4. Программалы чаралар исемлеге һәм аларны финанслау.

<table>
<tr><th>Чараның атамасы</th><th>Срок</th><th>Җаваплы башкаручылар</th><th>Финанслау чыганагы һәм күләме</th></tr>
<tr><td rowspan="2">1.Эре мөгезле терлекләрне нәтиҗәле үстерү буенча консультация</td><td rowspan="2">2015-2016</td><td>«Зеленый Дол» инвестиция үзәге» АУ</td><td>Муниципаль бирем кысаларында</td></tr>
<tr><td>Авыл җирлекләренең башкарма комитетлары</td><td>Җирлекләр бюджеты кысаларында</td></tr>
<tr><td>2.Хуҗалык итүнең кече формалары һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар эшчәнлеген</td><td>2015-2016</td><td>«Зеленый Дол» инвестиция үзәге» АУ</td><td>Муниципаль бирем кысаларында</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| консультацияләү һәм юридик яктан тәэмин итү | | | |
| 3. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга индивидуаль саву аппаратлары сатып алуга чыгымнар өлешен субсидияләү - НДСны исәпкә алмыйча, аларның хакының 60 проценты күләмендә | 2015-2016 | Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты «Зеленый Дол» инвестиция үзәге» АУ | Зеленодольск муниципаль районы бюджеты:<br>2015г - 540 000 сум<br>2016г. - 648 000 сум |